РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

13 февраль 2015 ел № 1-45

**«2014 елда Буа муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында»**

Буа муниципаль районы башлыгының 204 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, депутатлар билгеләп үткәнчә, Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге 2014 елда «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә халык мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырылды. Җирле үзидарәнең вәкиллекле һәм башкарма органнары эшчәнлегенең беренче чираттагы бурычлары арасында хуҗалык эшчәнлегенең барлык юнәлешләре буенча муниципаль берәмлекне үстерү программаларын кабул итү һәм гамәлгә ашыру, Буа муниципаль районы Советы карарларының җирле үзидарә органнарының җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан үтәлешен һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тикшереп тору булуын билгеләп үтеп, Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. 2014 елда Буа муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында хисапны игътибарга алырга.

2. Буа муниципаль районы Советы депутатларына 2014 елда Буа муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында хисапны үз округларында сайлаучылар игътибарына җиткерергә.

3. Буа муниципаль районы Советы Аппаратына хисап докладында һәм фикер алышканда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.

4. Буа муниципаль районы башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- хисап докладында һәм аның турында фикер алышканда әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә һәм депутатларга 2015 елның 1 апреленә кадәр мәгълүмат бирергә;
- җитештерү күләмнәрен үстерүне тәэмин итү, социаль тотрыклылыкны саклау чараларын күрергә;
- индивидуаль торак төзелеше темпларын саклап калу өчен чаралар күрергә, торак төзелешен алга таба үстерү өчен җирләрдән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә;
- белем бирүнең сыйфатын яхшырту чараларын күрергә;
- муниципаль берәмлек территориясендә законлылыкны һәм хокук тәртибен саклауны тәэмин итәргә;
- районның социаль-икътисадый үсеш программаларын алга таба гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә, районның икътисадый, мәдәни, рухи һәм иҗтимагый тормышында гражданнарның тулы кыйммәтле катнашуы өчен уңай шартлар тудыру;
- 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына район бюджетының керем өлешен үтәүне тәэмин итәргә.

5. Авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- территорияләрне комплексны социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- яшьләрне авылда калдыру һәм авыл халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү өчен кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләреннән мөмкин кадәр күбрәк файдалану;

- халыкның тормыш дәрәҗәсен киметүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүләргә тигез керүен тәэмин итү чараларын күрергә;

- хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм абруен ышанычлы яклауны тәэмин итү буенча, җирле потенциалны максималь файдаланып, алга таба да эш алып барырга;

- торак пунктларны яшелләндерү һәм санитар чистарту, экологик иминлекне тәэмин итү чараларын дәвам итәргә;

6. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе А.К. Айзетуллов